ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar. ru

# КАРАР

**23 декабрь 2025 ел** **№101**

**Пиротехник эшләнмәләрдән файдалану
өчен рөхсәт ителгән урыннарны
билгеләү турында**

Яңа ел бәйрәм чаралары чорында гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне тәэмин итү максатларында, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм “Янгын куркынычсызлыгы турында”1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында” 22.12.2025 1121 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Биеклеге 50 метрдан артык булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә, салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә, һава киңлегеннән файдалану Россия Федерациясе Һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасының оператив органы рөхсәте белән гамәлгә ашырыла (алга таба - Вәкаләтле орган).

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.”

2. Пиротехник эшләнмәләрдән файдалану өчен рөхсәт ителгән урыннар дип түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Шушмабаш авылы төньякка таба Носы авылы ягына таба, торак пункттан 300 метр ераклыкта;
- Шека авылы төньяк-көнбатыш юнәлештә 1 нче йорттан 300 метр ераклыкта Ворошилов урамы Шека авылы;
- Нусы авылы төньякка таба, 300 метр Сәрдәбаш авылы ягына таба юл чатында;
- Сәрдәбаш авылы көньяк юнәлештә, 300 метр Нуса авылы ягына таба;
- Илдус авылы төньякка таба, 300 метр Шушмабаш авылы ягына таба;
- Үгез-Елга авылы көньяк-көнбатыш юнәлештә, торак пункттан 300 метр ераклыкта;
- Ишнарат авылы көньяк юнәлештә, торак пункттан 300 метр ераклыкта.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Шушмабаш авыл

җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Шушмабаш авылы, Габделхай Каримов урамы, 1Б йорты; Носы, Татарстан урамы, 45 йорт.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Шушмабаш авыл җирлеге
башлыгы В.В.Сәгыйтов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1121690000143 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609012607